КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 август г.Казань № 791

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлегенә һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, ихтыярыйлык, хәйриячелекне үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасының коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе раслау турында» 2021 ел, 18 август, 744 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлегенә һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, ихтыярыйлык, хәйриячелекне үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасының коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан

Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе раслау турында» 2021 ел, 18 август, 744 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлегенә һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, ихтыярыйлык, хәйриячелекне үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

2.2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки заявка бирүченең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

3.1 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җитәкчегә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бер кеше башкарма органы функцияләрен башкаручы затларга яисә заявка бирүченең баш хисапчысына (баш хисапчы булганда) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтәләр һәм (яисә) Федераль салым хезмәте тарафыннан расланган формалар буенча соратып алынган мәгълүмат булмау турында белешмәләр;»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкалар Министрлык тарафыннан кабул ителә.

Министрлык, субсидия бирүгә каралган тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында расланган көннән алып җиде эш көне эчендә бердәм порталда һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 5.8 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләрне һәм заявка бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен аның тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 3.1 һәм 3.8 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

бу Тәртипнең 4.2 һәм 4.6. пунктлары нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 4.2 – 4.5 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм шулай ук сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый торган Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасы;

бу Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә сайлап алу критерийларын һәм бу Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә бәяләү критерийларын.»;

4.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Министрлык тарафыннан сайлап алуга кертелгән заявкаларны карау һәм бәяләү, сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турында яисә заявка бирүченең заявкасын кире кагу турында карар кабул итү максатларында, шулай ук субсидия алучының алынган субсидия күләме чикләрендә чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турындагы мөрәҗәгатен карау максатларында конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә. Комиссия составы Министрлык хезмәткәрләреннән һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләреннән төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссиянең составы биш кешедән ким һәм җиде кешедән артык була алмый.»;

5.2 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен субсидия алучының җаваплылыгы, шул исәптән субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү

тәртибен һәм шартларын бозган өчен (кирәк булганда кулланыла торган) штраф санкцияләре;»;

түбәндәге эчтәлекле 5.2[1] пункт өстәргә:

«5.2[1]. Субсидия алучы Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында шартнамәләр (килешүләр) төзегәндә аларга түбәндәге шартларны кертергә тиеш:

субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турында;

Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән субсидия алучыдан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтарткалда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу турында.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю;»;

6.1 пунктта «казанышлар турында» сүзләрен «күрсәткечләргә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6.1[1] пункт өстәргә:

«6.1[1]. Субсидия алучы алынган субсидия күләме чикләрендә чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлык, субсидия алучының мөрәҗәгате кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә мөрәҗәгатьне карау буенча Комиссия утырышын оештыра.

Комиссия әлеге пунктның икенче абзацында билгеләнгән срокта субсидия алучының мөрәҗәгатен карый һәм проектнычыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү яисә яңадан бүлүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә.

Министрлык комиссия утырышы беркетмәсе төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турында комиссия карар кабул иткән очракта, Министрлык, карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк формалар нигезендә субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү төзи.”;

6.3 пунктта:

икенче абзацта «шартлар» сүзен «шартлар һәм тәртип» сүзләренә, «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«A = \left(\sum_{i=1}^{4}\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,»;$$

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

6.6 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

2.2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки заявка бирүченең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

3.1 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җитәкчегә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бер кеше башкарма органы функцияләрен башкаручы затларга яисә заявка бирүченең баш хисапчысына (баш хисапчы булганда) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтәләр һәм (яисә) Федераль салым хезмәте тарафыннан расланган формалар буенча соратып алынган мәгълүмат булмау турында белешмәләр;»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкалар Министрлык тарафыннан кабул ителә.

Министрлык, субсидия бирүгә каралган тиешле финанс елына һәм план чорына

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында расланган көннән алып җиде эш көне эчендә бердәм порталда һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 5.8 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләрне һәм заявка бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен аның тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 3.1 һәм 3.8 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

бу Тәртипнең 4.2 һәм 4.6. пунктлары нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 4.2 – 4.5 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм шулай ук сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый торган Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасы;

бу Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә сайлап алу критерийларын һәм бу Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә бәяләү критерийларын.»;

4.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Министрлык тарафыннан сайлап алуга кертелгән заявкаларны карау һәм бәяләү, сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турында яисә заявка бирүченең заявкасын кире кагу турында карар кабул итү максатларында, шулай ук субсидия алучының алынган субсидия күләме чикләрендә чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турындагы мөрәҗәгатен карау максатларында конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә. Комиссия составы Министрлык хезмәткәрләреннән һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләреннән төзелә һәм Министрлык

боерыгы белән раслана. Комиссиянең составы биш кешедән ким һәм җиде кешедән артык була алмый.»;

5.2 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен субсидия алучының җаваплылыгы, шул исәптән субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын бозган өчен (кирәк булганда кулланыла торган) штраф санкцияләре;»;

түбәндәге эчтәлекле $5.2^1$ пункт өстәргә:

«$5.2^1$. Субсидия алучы Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында шартнамәләр (килешүләр) төзегәндә аларга түбәндәге шартларны кертергә тиеш:

субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турында;

Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән субсидия алучыдан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу турында.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю;»;

6.1 пунктта «казанышлар турында» сүзләрен «күрсәткечләргә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $6.1^1$ пункт өстәргә:

«6.1[1]. Субсидия алучы алынган субсидия күләме чикләрендә чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлык, субсидия алучының мөрәҗәгате кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә мөрәҗәгатьне карау буенча Комиссия утырышын оештыра.

Комиссия әлеге пунктның икенче абзацында билгеләнгән срокта субсидия алучының мөрәҗәгатен карый һәм проектнычыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү яисә яңадан бүлүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә.

Министрлык комиссия утырышы беркетмәсе төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Чыгымнар юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турында комиссия карар кабул иткән очракта, Министрлык, карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк формалар нигезендә субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү төзи.”;

6.3 пунктта:

икенче абзацта «шартлар» сүзен «шартлар һәм тәртип» сүзләренә, «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«A = \left(\sum_{i=1}^{3}\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,»;$$

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.».

6.6 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының илле дүртенче һәм йөз сигезнече абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлне туктатырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә һәм социаль партнерлыкны,

граждан инициативаларын, ихтыярый булуны, хәйриячелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 август, 744 нчы карары белән расланган Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә һәм социаль партнерлыкны, граждан инициативаларын, ихтыярый булуны, хәйриячелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенең 2.2 пунктының өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә һәм социаль партнерлыкны, граждан инициативаларын, ихтыярый булуны, хәйриячелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 август, 744 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенең 2.2 пунктының өченче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин